КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 июль г.Казань № 668

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы белән Татарстан Республикасы халкына концессион килешү объекты бүлмәләрендә медицина хезмәтләре күрсәтүне күздә тоткан концессион килешү төзегән юридик затларга чыгымнарын кайтаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 3 июль, 458 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы белән Татарстан Республикасы халкына концессион килешү объекты бүлмәләрендә медицина хезмәтләре күрсәтүне күздә тоткан концессион килешү төзегән юридик затларга чыгымнарын кайтаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы белән Татарстан Республикасы халкына концессион килешү объекты бүлмәләрендә медицина хезмәтләре күрсәтүне күздә тоткан концессион килешү төзегән юридик затларга чыгымнарын кайтаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 3 июль, 458 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы белән Татарстан Республикасы халкына концессион

килешү объекты бүлмәләрендә медицина хезмәтләре күрсәтүне күздә тоткан концессион килешү төзегән юридик затларга чыгымнарын кайтаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыруына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра; дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин